**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы № 117 15 октябрь 2024 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы карар проекты турында

Җирле үзидарә турындагы федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы карар проектын кабул итәргә. (№1 кушымта)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, 2024 елның 22 октябреннән дә соңга калмыйча, Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Сарлы авыл җирлеге» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 18 ноябрендә 17.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авылы, Үзәк ур. 68А үткәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы Сарлы авылы, Үзәк ур. 68А дип билгеләргә.

5. Гавами тыңлауларны үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Камалетдинов И.М. Сарлы авыл җирлеге Башлыгы;
- Сахапов Р.Р. Сарлы авыл җирлеге депутаты;
- Миңнеханов Д.Н. Сарлы авыл җирлеге депутаты;

6. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне, тәкъдимнәрне исәпкә алуны гавами тыңлаулар уздыру буенча эшче төркемгә тәкъдим итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссия утырышында яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Камалетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы ______авыл җирлеге Советының 2024 елның 15 октябрендәге №____ карарына №1 кушымта

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 23 гыйнварындагы ______ номерлы ________________ авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «_______ авыл җирлеге» Уставына (24.09.2012 №__, 05.08.2013 №__, 22.10.2014 №__, 30.09.2015 №__, __.11.2016 №__, 17.04.2018 №__ 03.09.2018 №__, 05.11.2019 №__, 17.11.2020 №__, 25.02.2022 №___, 16.02.2024 №__ карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20 пунктны өстәргә:

"20) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»

1.2. 19.1 статьяның 5 пунктындагы абзацта ике пунктны «1-7 пунктлары» сүзләрен «1-7 һәм 9_2 пунктлары» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 29 статьяда:

а) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 39 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

"10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

б) 2 өлештә «1-7, 10 һәм 11 пунктларында» сүзләрен «1-7, 10, 10.1 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 44 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын төшереп калдырырга.

1.6. 47 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзацны өстәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыра.»

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвеннән соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru,  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakayevo.tatarstan.ru, __________авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында  бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.